| СОВЕТ БУРБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ**
«24» сентябрь 2019 ел.

**КАРАР**
№122

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасының 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законы, 2004 елның 24 мартындагы «Татарстан Республикасында җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге Уставының 11 нче статьясы, Бөрбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 сентябрендәге "Бөрбаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм аларны куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында" №121 карары, Бөрбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 18 сентябрендәге "Бөрбаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм аларны куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында" №35 карары нигезендә , Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге территориясендә 2019 елның 17 ноябрендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелгән сорауларны расларга:

"Сез 2020 елда референдумда тавыш бирү хокукына ия булган 18 яшькә җиткән Бөрбаш авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Бөрбаш авылында: торак пункт чикләрендә яр буенда агачлар, куаклар кисү һәм Кадермәт елгасы үзәнен төзекләндерү;
- Алан авылында: Советская-С.Садыйкова, Пионерская урамнарындагы юлларны өлешчә ремонтлау;
- Бөрбаш-Сәрдегәне авылында: балалар уен мәйданчыгы урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү, Г.Зарипов урамында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

**ӘЙЕ** **ЮК**

3. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономияләгәндә, Бөрбаш авыл җирлеге Советы карары нигезендә, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны Балтач районы "Хезмәт" газетасында бастырырга, Татарстан Республикасы pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Балтач муниципаль районы
Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Галимуллин